
# Нәби Дәүли (1910-1989)




Нәби (Нәбиулла) Дәүли (Дәүләтшин) Хәсән улы

Сугышта солдат гомере
Була диләр бик кыска.
Ышанмагыз, дөрес түгел,
Солдат үлми сугышта.
Кинәт ут булып яна ул,
Я давыл булып үтә.
Халык телендә кала ул,
Җыр булып гомер итә.

1910 елның 1 нче июнендә элекке Казан губернасының Спас өязе (хәзер Татарстан Республикасының Әлки районы) Иске Камка (борынгырак исеме – Мәүләшә) авылында Хәсән Миндубаев исемле игенче гаиләсендә туа.



- Дүрт яшендә чагында әтисе авырып үлә, ә әнисе Ставрополь шәһәренә күченеп китә. Шунда Нәбиуллаңың әнисе дә кинәт вафат була. Ятим бала балалар йортында тәрбияләнә.







Хәрби хезмәттән  соң, Н.Дәүли Казанга килә һәм Ватан сугышы башланганга кадәр Татарстан Республикасы яшьләр газетасында ( “ *Яшь сталинчы” хәзерге “Татарстан яшьләре ”)* әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.



Сугышның беренче көннәрендә үк Нәби Дәүли фронтка китә. Ләкин 1941нче елның август аенда, Орша шәһәре янында барган авыр бәрелешләрдә чолганышка эләгеп,  әсир төшә.







Башта ул берничə ай Бухенвальдта тотыла, аннары Баден-Баден, Магдебург шəһəрлəре янындагы үлем лагерьларында газап чигə.



1945 нче елның апрелендә, Н. Дәүли берничә иптәше белән лагерьдан кача. Сугышның соңгы айларында ул Совет Армиясе сафында солдат хезмәтен дәвам иттерә.

“Концентрацион лагерьларда, төрмәләрдә, газ камераларында үтерелгән миллионлаган кешеләр турындагы сагышларны истән чыгарып буламы? Ятим калган балаларның, ялгыз калган аналарның йөрәкләренә тирән яра булып салынган кайгыны онытып буламы?” Нәби Дәүли






Нәби Дәүли татар язучылары белән ялда. 1950 ел



Нәби Дәүли гаиләсе белән



“ **Яшь кеше!** Әгәр син, иртә белән тыныч йокыдан уянгач, тәрәзә төбендә ефәк яфраклы гөлләрнең чәчәк атуын күрсәң, әгәр син шул иртәдә өй каршындагы тирәкләрдә кошларның сайравын ишетсәң, бел – бу иртәнге шатлыкта сугышта үлеп калган солдатларның, фашизм тоткынлыгында һәлак булган ватандашларыңның ялкынлы тормышы бар. “

Нәби Дәүли

Жанр торлелеге купкырлы була язучынын. Аның: сәяхәтнамә, нәсер, юлъязма, хикәя, проза әсәрләре, юмореска, фельетон, автобиографик әсәрләр, тәнкыйть мәкаләләре, курчак театры өчен пьесалар, шигырь








# Дәүләт бүләкләре

Нәби Дәүли “ Почет Билгесе “ ордены (1980) һәм Татарстан Верховный Советы Президиумының Мактау грамоталары белән бүләкләнгән.

Дәүләтшин Нәбиулла Хәсән улы “ ***Фашистларның Бухенвальд – Дора үлем лагерьларында фашистларга каршы азатлык көрәшендә катнашучы*** “ медале белән бүләкләнә (үзе үлгәч).

Нәби Дәүли исемен **мәңгеләштерү** максатыннан

1) Казандагы бер урам Нәби Дәүли исеме белән атала;
2) Глактионов урамында алар яшәгән йортка мемориаль такта куела;
3) 2010 елда "Яшәү белән үлем арасында" китабы тагын бер кат бастырып чыгарыла;
4) китапның русча Брайль системасындагы варианты да эшләнә .

# Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

Күгәй авылы китапханәсе,әйдәп баручы китапханәче
Гафарова Гөлсу вәрис кызы